

27 январендә Рузаевка районы жыр, бию, шигырь «Созвездие талантов» республикабыз фестивалендә Инсар, Кадошкино, Ләмберә, Кочкурово, Рузаевка район укучылары катнашкан.
Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 11 сыйныф укучысы Кузикова Самира - сәләт иясе. Ул татар әдәбияты олимпиадары жинvчесе һәм бу фестивальдә дә Хади Такташнын «Ак чәчәкләр»ен башта татар телендә, ә азагын рус телендә сәнгатьле сойләп, лаеклы беренче урынны яулый. Бу бердән-бер авыл мәктәбе укучысы районнарынын мактаулы исемен яклаган.

Cvз унаеннан. Унынчы сыйныф укучысы Диана Илларионова татар әдәбияты олимпиадасынын мәктәп-муниципаль турларында - беренче, ә регионда - икенче. Бу укучыларга татар теле һәм әдәбияты предметларына мәхәббәт тәрбияләvче, белем бирvче Сания Спартак кызы Саляева. Сания Спартаковнанын укучылары «Такташ укулары»нда да алдынгылар. Кузикова Самира тагын жинvче, ә 6 сыйныф укучысы Мансур Золуков – 2 нче дәрәжә призеры. Дипломнар белән грамоталарын якын арада тапшырачаклар.
Тиздән республика кvләмендә «Жә-лил укулары» дигән ижади конкурс vтәр, ана әзерләнәләр.